

Агымдагы елда юлларны ремонтлау һәм юл тозелеше турында Мордовиянен Транспорт һәм юл хужалыгы буенча Дәvләт комитеты рәисе Василий Понедельников белән Саранск шәһәр округы житәкчесе Владимир Быков Матбугат vзәгендә vткән конференциядә сойләделәр.
Василий Понедельников респуб-ликада 2026 елда жәелдереләчәк юл эшләренен масштабы турында хәбәр итте. Ул:
- Агымдагы елнын 12 маена юл эшләре гомуми озынлыгы 166 км булган, бәясе 8 млрд 760 млн сумлык 77 объектта планлаштырылган. «Яшәv очен инфраструктура» милли проектын гамәлгә ашыру кысаларында 131 км озынлыктагы, 7 млрд 328 млн сумлык 30 объектта чаралар планлаштырылган.
«Авыл территорияләрен комплекслы vстерv» дәvләт программасы буенча 9 км озынлыктагы 9 объектта 488 млн сумлык чаралар планлаштырылган. Субсидия кысаларында Мордовия Республикасы юл фондыннан vз акчалары хисабына 25,5 км озынлыктагы, бәясе 943 млн сум булган 38 объект ремонтланачак.
Мордовия транспорт һәм юл хужалыгы буенча Дәvләт комитеты рәисе агымдагы елда рес-публика житәкчелеге тобәк юл фонды акчаларын жирле юл челтәренә зур кvләмдә юнәлтv турында Карар кабул иткәнен билгеләп vтте.
- Хәзерге вакытта капиталь ремонт, ремонт, жирле юллар тозvгә субсидияләр бирvгә конкурс буенча сайлап алу дәвам итә. Саранск шәһәр округыннан тыш, автомобиль юлларынын тагын 38 учас-тогына гариза документларын 18 муниципаль берәмлек тапшырган (Ардатово, Атюрьево, Атяшево, Большое Игнатово, Ельники, Зубова Поляна, Ичалки, Ковылкино, Кочкурово, Краснослободск, Ләмберә, Рузаевка районнары, Рузаевка шәһәре, Старо-Шайгово, Темников, Теньгушево, Чамзинка районнары, Явас хезмәт поселогы). Узган ел Мордовия юл фондыннан 9 муниципалитетка 25 жирле юлны норматив хәлгә китерv очен 622 млн сум кvләмендә субсидия бирелгән булса, быел монарчы кvрелмәгән сумма бирелә; без барлык муниципалитетларга да субсидияләр бирvне тәэмин итәргә планлаштырабыз! - дип ассызыклады Мордовиянен Транспорт һәм юл хужалыгы буенча Дәvләт комитеты рәисе. Агымдагы елда муниципаль берәмлекләргә Мордовия Республикасынын юл фондыннан якынча 2,4 млрд сум кvләмендә субсидияләр бvлv планлаштырыла.
Саранск мәры Владимир Быков Мордовия башкаласындагы юл эшләре турында сойләде.

- Мордовия Республикасы Главасы һәм Мордовия Республикасы Хокvмәте ярдәме белән шәһәр округына Юл фондыннан якынча миллиард ярым сум акча бирелде. Хәзерге вакытта 37 юлны ремонтлауга бер миллиард сумлык контрактлар имзаланган. Жиде юлда инде эшкә керешкәннәр, Большевистская урамын ясаганнар. Кичәге коннән Красноармейская урамын ремонтлый башладылар, автовокзалдан Ключарево зиратларына кадәр юлда эшләр алып барыла, тиздән Советская белән Ботевградская урамнарында - кvпердән Васенко урамына кадәр эшләр башлана. Гарантия йокләмәләре буенча дvрт урам ясадык, хәзер Лодыгина урамы һәм Александровский шоссесы киселешендә эшләр башкарыла: ул бик нык жимерелгән. Шулай ук тоньяк-кончыгыш

шоссесын ремонтлауга керешәбез. 12 майга чокырларны ремонтлау буенча без 19 урамны нормативларга туры китердек, - дип хәбәр итте шәһәр житәкчесе.
Саранскида конкурс процедураларын vткәрv нәтижәсендә бюджет акчаларын экономияләv кvзәтелә; алар республика жи-тәкчелеге белән килешv буенча берничә урамны - Энгельс, Ульянов һәм Пушкин урамнарын ремонтлауга юнәлдереләчәк. Зыян кvргән юл ослегеН монда зур карталар белән торгызу планлаштырыла, чонки чокырларны ремонтлау теләгән нәтижә бирмәячәк. Шулай ук Мордовия башкаласында 47 тротуар һәм 150 ишегалдына ремонт ясау каралган. Шунысын да билгеләп vтәргә кирәк, конкурс процедуралары барышында бюджет акчаларын экономияләv нәтижәсендә Саранскида быел тагын утыз ишегалдын янарту кvздә тотыла.
- Ремонт кампаниясенен барышын мин шәхсән контрольдә тотам, барлык участокларны шәхсән узам», - дип ышандырды Владимир Быков.
Мордовия Республикасы транспорт һәм юл хужалыгы буенча дәvләт комитеты рәисе Василий Понедельников билгеләп vткәнчә, республиканын топ капитал таләп итvче юл объектларында эшләр актив фазада бара. Сvз Рузаевка шәһәренен Бедно-Демьяновская урамындагы тимер юл аша кvперне ремонтлау, «Ковылкино - Краснослободск - Ельники - Первомайск» автомобиль юлында тимер юл аша юлvткәргеч белән транспорт чишелеше һәм Строительная урамы буйлап Победы урамыннан Гожувская урамына кадәр, тимер юл һәм Инсар елгасы аша юлvткәргечне дә кертеп, автомобиль юлы тозv турында бара. Бу юлларда транспорт хәрәкәте быелнын сентябрендә vк эшли башларга момкин дигән алшартлар (предпосылки) бар. Сез, сылтамалар буенча, Саранск шәһәр округындагы юлларны һәм тротуарларны ремонтлау карталары белән таныша аласыз.

**Наилә НАСЫРОВА**